Чыганак: Мирас.- 2012.- № 2-3.- Б.24-30



# 1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА ҺӘМ 1813-1815 ЕЛЛАРДАГЫ РУС АРМИЯСЕНЕҢ ЧИТ ИЛ ПОХОДЛАРЫНДА ТАТАРЛАР

ИЛШАТ ФӘЙЗРАХМАНОВ,
*тарих фәннәре кандидаты*



Петр I чорыннан алып 1874 елга кадәр төп өлеше дәүләт крестьяннары саналган татарларның армиягә дәүләт алдында рекрутлар бирү йөкләмәсе булган. 1793-1834 елларда армиядә хезмәт итү вакыты 25 ел тәшкил иткән. Гадәти елларда мең кешедән 5-7 кеше армиягә алынса, сугыш алдыннан һәм сугыш вакытында көчәйтелгән (1 мең ревизия җанынннан 7-10 кеше) һәм өстәмә (1 мең ревизия җанынннан 70 кешегә кадәр) рекрут наборлары үткәрелгән. 1812 елда исә 3 тапкыр армиягә алу була: 82 нче (1 мең кешедән дүртешәр рекрут), 83 нче (1 мең кешедән 20 рекрут), 84 нче (1 мең кешедән 16 рекрут)[1]. Даими армиядә хезмәт итүче татар солдатлары Наполеон гаскәрен җиңүгә зур өлеш кертә.

1812 елның сентябрендә Казан ополчениесен җыю башлана. Ополчениегә крепостной крестьяннар (100 кешедән 4се) алына. Дәүләт крестьяннары, шул исәптән татарлар, ополчениегә чакырылмый, шулай да шәһәрдә яшәүче мещаннардан, һөнәрчеләрдән баручылар була. Мәсәлән, Нигабидуллина фамилияле мещан сословиесеннән татар хатыны ополчениегә олы улын бирә. Алай гына түгел, Татар шәһәр ратушасына барып, кече улын да ополчениегә алуларын сорап йөри[2].

1812 елның көзенә Казанга Мәскәүдән һәм Смоленскидан 30 меңләп качак китерелә. Казанда качакларга зур ярдәм күрсәтәләр: монастырьларга һәм казанлылар йортларына урнаштыралар.

Сугыш башыннан алып армия, ополчение һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү өчен иганә кампанияләре үткәрелә. Казан губернасы буенча барлык иганә җыемнары 346 мең сум тәшкил итә. Җыйналган алтын-көмеш арасында татар хатын-кызлары тапшырган бизәнү әйберләре дә була. Армия өчен кирәк-ярак җыю ирекле-мәҗбүри характерда алып барыла. Казанның татар общинасыннан 1812 елның 3 июленә 2 нче Кострома пехота полкын оештыруга 4100 сум җыела. 1812 елның 21 августында Татар шәһәр ратушасына караган сәүдәгәрләрдән мәҗбүри 8360 сум җыю карала. Шәһәрнең рус мещан сословиесе общинасы 10 мең сум тирәсе ярдәм акчасы җыеп бирә[3].

Франция белән сугыш чыгар алдыннан, бай Казан сәүдәгәрләренең күбесе Мәкәрҗә ярминкәсенә киткән була. Ярминкәдә Түбән Новгород губернасы ополчениесенә иганә акчасы җыела. Ярдәм итүчеләр арасында ярминкәгә Түбән Новгородтан, Мәскәүдән, Казаннан, Тобольскидан, Иркутскидан һ.б. төбәкләрдән килгән сәүдәгәрләр була. Иганәчеләр исемлегендә Казанның I гильдия сәүдәгәре Муса Исмәгыйль улы Апанаев (520 сум), Малмыж шәһәренең I гильдия сәүдәгәре Муса Үтәмышев (500 сум), Арча шәһәренең I гильдия сәүдәгәрләре Мөхәммәтрәхим Мәмәшев, Мортаза Борнаев, Габделкәрим Бакаров (йөзәр сум) һ.б. исемнәре язылган.

[1] Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т.32. – №25198.

[2] Городчанинов Г. Казанское ополчение // Газета «Республика Татарстан». – 2002. – 12 сент.

[3] Валиуллин И. «На пожертвование в пользу Отечества» (Татарская община г. Казани в 1812 г.) // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2009. – № 1. – С.10-12.

1812 елның 8 августында Мәкәрҗә ярминкәсенең Татар сабын рәтеннән генә дә Казаннан килгән татар һәм рус сәүдәгәрләре 5690 сум тапшыра. Мәкәрҗә ярминкәсе барышында җәмгысе 72746 сум иганә акчасы җыела. Чагыштыру өчен: Түбән Новгород губернасы буенча җыемнарның гомуми күләме 875 мең сумнан артып киткән[4].

Татарларның бер өлеше сугыш хәрәкәтләрендә даими булмаган хәрби формированиеләр составында катнаша.

Башкортлар, мещерякләр, типтәрләр, татарлардан торган казак полклары французларга каршы генераллар П.И.Багратион, А.И.Тормасов, М.Б.Барклай де Толли армияләре составында сугышкан. Монда берничә төркем хәрби көч була: башкорт һәм мещеряк полклары, Оренбург казак гаскәре, типтәр казак полклары.

Мөселман хәрби формированиеләрдән, беренче чиратта, башкорт һәм мещеряклардән торган полкларны атап үтәргә кирәк. Алар Пермь, Оренбург һәм Вятка губерналарында 1798 елда кантон системасы төзелгәч оештырыла[5]. Гаскәрләрне Оренбург саклану линиясе буенча казахлар белән ике арадагы чикне саклауда файдаланалар.

[4] Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть — центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX — начало XX вв.). — Нижний Новгород, 2006. — С.30.

[5] Полное собрание законов Российской империи. Собрание 1-е. Т.27. — №18477.



Хәрби министрлыкның 1812 елның 25 июль боерыгы нигезендә 3, 4, 5 нче башкорт полклары оештырыла. Шул ук елның июлендә өстәмә атлы полклар оештыру тәкъдиме белән Оренбург казак гаскәре атаманы В.А.Углецкий чыга. Аның тәкъдимен Александр I хуплый. Инде 1812 елның август-сентябрендә 1 нче, 2 нче мишәр һәм тагын 15 (6-20 нче) башкорт полклары оештырыла. Һәр полкта 530 кеше исәпләнелә (500 рядовой, полк начальнигы, старшина, 5 есаул, 5 сотник, 5 хорунжий, 10 пятидесятник, квартирмейстер, писарь һәм мулла)[6].

Башкорт һәм мещеряк полкларының махсус мундиры булмый, алар үзләренең милли киемнәрен киеп сугышка китә, сөңге, кылыч, ук-җәя белән коралланган була. Мылтык һәм пистолетлар бик сирәк сугышчыда гына була. Чөнки хөкүмәт аларга коралл ану өчен акча бирми.

Башкорт полклары французлар белән күпсанлы бәрелешләрдә катнаша: французларны Россиядән куганда, Березина янында бәрелештә, рус армиясенең Чит ил походында, шул исәптән 1813 елның 4-7 октябрь көннәрендә «Халыклар сугышы» исеме белән тарихка кереп калган Лейпциг сугышында һ.б. Алар шулай ук әсирләрне саклыйлар, каравыл һәм тәртип саклау вазифаларын башкаралар[7].

Оренбург казак гаскәре күп милләт вәкилләреннән торган. 1799 елда гаскәргә Оренбург губернасының ясаклы крестьяннары һәм татарлары кертелә. Французларга каршы Оренбург казак полклары составында татар-мөселманнардан тыш ногайбәкләр — чукындырылган татарлар да катнаша. Ногайбәкләр походтан соң туган якларына кайткач һәм күпмедер вакыттан соң яңа урынга күченгәч, поселокларын үзләре җиңүчеләр булarak үткән Европа шәһәрләре исемнәре белән (Париж, Берлин, Фершампенуаз, Арси, Кассель һ.б.) атыйлар.

XVIII гасыр ахырында оешкан типтәр полклары статуслары буенча регуляр һәм иррегуляр кавалерия гаскәрләре «арасында» булалар. Бер яктан, аларга хәрби мундир, корал бирелгән, билгеле бер хезмәт итү срогы (15 ел) билгеләнгән, икенче яктан, полкның тәэмин ителеше, аның типтәрләр һәм бобыльләр сословиесе вәкилләреннән генә оешканлыгы, чиннар һәм оештыру тәртибе иррегуляр гаскәрләрдәге сыман булган[8].

Сугыш башланганда 1 нче типтәр полкы инде генерал М.Б.Барклай де Толлиның 1 нче Көнбатыш армиясе составында була. Бородино сугышында әлеге полк М.И.Платов һәм Ф.П.Уваров җитәкчелегендәге рус атлы гаскәренең француз тылына рейдында катнаша. 1812 елның сентябрь-октябрь айларында хәзерге Калуга өлкәсендә һәм янәшәдәге Смоленск, Мәскәү өлкәләрендә 1 нче типтәр полкы башка частьлар белән бергә актив хәрәкәт итә. Аларга дошман тылына һөҗүмнәр оештыру, француз армиясен азык-төлек, корал белән тәэмин итүне тоткарлау, мародерлар белән көрәш вазифалары йөкләнә[9].

[6] Усманов А.Н. Башкирский народ в Отечественной войне 1812 г. – Уфа, 1964. – С.56.

[7] Бекмаханова Н., Кобландин К. Французской кавалерии лучше бы не сходиться со степняками // Татарский мир. – 2002. – №3. – С.5.

[8] Рахимов Р.Н. История тептярских конных полков. 1790–1845. – Уфа, 2008. – С.188.

[9] Ахметшин Ш.К., Насеров Ш.А. Татары на службе Отечеству. Долг. Отвага. Честь. Страницы истории татарских воинских частей в Российской армии и Императорской гвардии. – СПб., 2006. – С.165-166.

2 нче типтәр полкы 1812 елның сентябрендә Денис Давыдовның партизан отряды составында Вязьма шәһәре янында һәм Яңа Смоленск юлында французларга каршы хәрәкәт итә. Аннары полк ополченецлардан һәм иррегуляр гаскәрләрдән торган махсус корпус составында Смоленск губернасында дошманга каршы сугыша.

Күп татар сугышчыларының батырлыкларын командирлары югары бәяли. Мәсәлән, Вязьма өчен сугышта 1 нче типтәр полкы есаулы Сәгыйть Халитов үзен таныта — III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә[10]. Рославль шәһәре янында күрсәткән батырлыклары өчен полк командиры майор Тимиров — IV дәрәҗә Изге Владимир ордены белән, прапорщик Мөнасыйпов III дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә, зауряд-хорунжий Ибраһимовка — хорунжий чины бирелә[11].

1814 елның 18 мартында 4 нче һәм 5 нче башкорт, 1 нче һәм 2 нче типтәр полклары Россия гаскәре составында Парижга керәләр. Бу полк сугышчылары «1814 елның 19 мартында Парижны алган өчен» дип язылган көмеш медальләр белән бүләкләнә.

[10] Бекмаханова Н., Кобландин К. Күрсәтелгән хезмәт. — Б.5.

[11] Народное ополчение… — Б.161-162.

Шулай итеп, чик буен саклауда зур тәҗрибә туплаган атлы типтәр полклары, кавалерия һөҗүмнәре вакытында үзләренең югары дәрәҗәдә хәрби әзерлекле булуларын күрсәтәләр.

Наполеон Франциясен җиңүгә кырым татарларының дүрт атлы полкы да зур өлеш кертә. Бородино сугышында татар җайдаклары, французларның тылларына рейд ясауда катнашып, сугышка француз императоры гвардиясенең катышып китүен тоткарлауга зур өлеш кертә.

1812 елда Россия регуляр кавалериясе составында литва-польша татарларыннан торган Татар улан полкы була. Татар улан полкы сугыш башында генерал А.П.Тормасовның 3 нче Резерв армиясе авангардына керә, 1812 елның җәендә полк Кобрин янындагы, Литвадагы Городечке авылы янәшәсендәге сугышларда катнаша, Наполеонның төп көчләре белән бәрелешү французларның Березина елгасын кичкән вакытта була. Татар полкы уланнары дошман гаскәренең флангларына «кинжал» ударлар ясый һәм шунда ук кире үз позицияләренә кайта.

Литва-польша татарларының Наполеон ягында сугышучылары турында да әйтеп китәргә кирәк. 1812 елда Наполеон армиясе составына кергән аерым татар эскадроны (штаты: майор, 4 капитан, 7 лейтенант һәм су-лейтенант, 110 түбән чин) полковник Мостафа Әхмәт улы җитәкчелегендә сугыша. Вильноны саклаганда, эскадрон зур югалтуларга дучар була (10 офицер һәм 50 рядовой). Француз полкы составында эскадрон Германия, Франция территорияләрендәге сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, 1815 елда туган якларына кайтарып таратыла.

Сугышка Урал-Идел төбәгеннән киткән татарларның Наполеон армиясенә каршы сугышулары «Любизар», «Голубец,

молодец» кебек халык җырларында чагылыш тапкан. Патриотизм хисе белән сугарылган «Рус-француз сугышы бәете» татарларның рус армиясе җиңүенә керткән өлешен ачып бирә:

*[…] Французлар килеп кергән Мәскәү дигән калага;*
*Безнең гаскәр килгәчтен, алар качты далага. […]*

*Урамнарын тутырса да французлар Мәскәүнең,*
*Унике типтәр бетерде французның гаскәрен.*

*Дүрт-биш кердек сугышка, каннар билдин актылар,*
*Сугышларны бетергәч, безгә медаль тактылар.*

*Французның атлары бар да ефәк тышаулы;*
*Французның солдатлары офицерга охшаулы. […]*

*Французлар монда килгән, таныдылар үзләрен,*
*Уңда – башкорт, сулда – типтәр, табалмыйдыр эзләрен.*

*Французның илләре, түгәрәк икән күлләре,*
*Французларны куганда үттек без күп илләрне. […]*

*Французның атлары кырын җирдә дулыйдыр,*
*Башкорт белән типтәрләр французны турыйдыр. […]*

*Наполеонның эшләпәсе канга тапланган иде;*
*Без сугыштан кайтканда, илләр шатланган иде. […]*

Шулай итеп, 20 башкорт (аларның 13 е хәрби хәрәкәтләрдә катнаша), 2 типтәр һәм 2 нче мещеряк полклары, 4 кырымтатар полкы, литва-польша татарларыннан торган Татар улан полкы 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1814 еллардагы Чит ил походларында катнаша (1 нче мещеряк полкы Мәскәүдә калдырыла). Мөселман руханилары бу полкларда дини бурычларын үтәгәннәр, дин кардәшләрен Ватан һәм патша өчен көрәшкә рухландырып торганнар.

Ил-Ватан өчен көрәш, 200 ел элек безнең бабаларыбыз кылган батырлыклар, Россия дәүләтчелеген тагын да ныгыткан, бүген дә халык хәтерендә якты истәлек булып саклана. Тарихның аннан соңгы вакыйгалары, XX гасырның I, II Бөтендөнья сугышларында милләтебезнең сугышчан батырлыгы традицияләре тагын да ачыла. Г.Тукайча әйтсәк: «Уртак Ватанда, аның тарихында – без эзлебез». Уртак Ватанда безнең хокукларыбыз да тиң һәм гадел булырга тиеш.